

Бу рәсемдә язма героебызга егермедән артык яшь. Алда аны су асты коймесендәге ерак походлары котә иде.
Сихри доньяны анлап бетереп булмый шул; кvп нәрсәләрне сиземлибез, ә сихри коченә ышанырга теләмибез. Әмма тормышта анларга мәжбур иткән хәлләр дә була. Шулай, Ләмберә авылынын «Сельхозтехника» микрорайонында яшәvче Фатыйх Әхтәм улы Булатовнын безгә карап торган фотосы vзенә кvрә саклап торучы бетv-оберегка әйләнгән. Хәлләр шулай була. Агымдагы елнын язында аны хастаханәгә инсульт белән алып киткәч, якыннары ана нәкъ шул фотосын алып килеп, караваt янындагы тумбочкасына куялар. Яшьлеген искә тошереп, тормышта булган шатлык-куанычлары рәсемнән ана карап тора тосле һәм бу халәт авыруга каршы корәшv очен яна коч ости. Хәтта шәфкать туташлары да бу рәсемне йогереп килеп карап китә торган булганнар. Чыннан да, бу фотодан унай энергия боркеп тора. Хәер, бәлки, мондый хәлләр дә буладыр, чонки кешенен аны табышмаклары әлегә кадәр сер булып кала бит…      - Мине ул вакытта, 1965 елда ук, апам ялга килгәч фотога тошерде, - дип сойли Фатыйх Әхтәмович «Призыв» хәбәрчесенә. – Ул вакытта мина егермедән артыграк яшь иде. Дингезче идем - су асты коймәсендә хезмәт иттем; беренче статья старшинасы. Әх, ничек тиз уза вакытлар! Картлыкнын килvен, ә анын белән чирнен дә килеп житкәнен сизми дә калдым. Элек нык егет идем, шуна кvрә мине Оленья Губага, Тоньяк флотына хезмәткә алдылар. Су асты коймәсендә хезмәт иттем. Дорес, башта Ленинградта, Кронштадтта Сергей Миронович Киров исемендәге уку отрядында булдым. Аннары тоньякка озаттылар. Минем белән бергә Ләмберәдән Равиль Алукаев та тоньякка китте, тик ул башка су асты коймәсендә хезмәт итте.
Әлбәттә, хәрби хезмәттә башта кыенрак булды; климатнын кискен vзгәрvе, поляр тон һәм поляр кон... Мона шунда ук ияләшеп булмый. Тик без корыга караганда кvбрәк рейдта булдык. Ерак походларга да киттек. Бер тапкыр Урта дингездәге хәрби конфликт зонасында булырга туры килде. Коймәдә беренче номерлы әзерлеклелекне игълан иттеләр, һәм шуна без дежур тордык. Ярдан ерак тvгел яна боерык кына котеп йордек. Шокер, барысы да тыныч vтте. Ә хезмәт итәргә туры килгән иптәшләремә килгәндә, коллективыбыз дус иде. Су асты коймәсе очен бу бик моһим, чонки анда

vзенчәлекле атмосфера. Ябык кинлек vзен сиздерә, мона иялəшергә кирәк. Әмма безне, сугыш һәм сугыштан сонгы елларнын беренче балаларын, ә мин  - кырык дvртенче ел баласы – тормыш vзе аерым чыныктырды, шуна кvрә барлык кыенлыкларны да жинеп килдек.
Тормышта булган авырлыкларны жинеп яшәргә ойрәнгән Фатыйх Әхтәм улы Булатов әкрен генә авыруларны да жинәргә тырыша.

**Наилә Насырова**